БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30» 12 2020 ел № 390

**«2021 - 2023 елларга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү» муниципаль программасын раслау турында**

«Татарстан Республикасының дәүләт программаларын эшләү, гамәлгә ашыру һәм аларның нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен һәм Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген раслау турында» 2012 елның 31 декаберендәге 1199 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын үтәү йөзеннән, Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. «2021 - 2023 елларга Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү» муниципаль программасын кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль учреждениеләренә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетын формалаштырганда һәм аның үтәлешен оештырганда Программаның нигезләмәләренә таянып эш итәргә.

3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының финанс-бюджет палатасына ел саен чираттагы финанс елына район бюджетын формалаштырганда, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджетыннан күрсәтелгән максатларга җибәрелә торган акчалар кысаларында һәм мөмкинлекләрне исәпкә алып, Программа чараларын гамәлгә ашыруга акчаларны күздә тотарга.

4. Әлеге карарны Интернет-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче А.Ф. Хәйретдинов